СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.01.2016 д. им. М. Вахитова № 5-32

«Югары Ослан муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә урнашкан, җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзекләндерүнең расланган кагыйдәләре булганда, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 августындагы 52-286 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә урнашкан, җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзекләндерүнең расланган кагыйдәләре булганда, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 августындагы 52-286 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы А.Ш. Залялетдинов